КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 14 апрель г.Казань № 404

«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» 2025 елның 26 декабрендәге 89-ТРЗ Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру буенча кайбер чаралар турында

«Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып баруны үстерү турында» 2025 елның 26 декабрендәге 89-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 нче өлешенең 2 – 6 пунктлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектларына кертү критерийлары;

Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусын бирү, озайту, туктату турында нигезләмә;

бизнесны җаваплы алып бару өлкәсендә дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә республика башкарма хакимият органнарының һәм Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламенты;

Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары реестрын булдыру һәм алып бару турында нигезләмә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче, 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы, 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы, 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче, 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче, 2012 ел, 3 февраль, 81 нче, 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче, 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы, 2013 ел, 14 март, 159 нчы, 2013 ел, 8 апрель, 238 нче, 2013 ел, 4 июнь, 384 нче, 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче,

2013 ел, 31 октябрь, 818 нче, 2014 ел, 13 август, 590 нчы, 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче, 2015 ел, 20 март, 174 нче, 2015 ел, 4 июнь, 407 нче, 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче, 2016 ел, 6 август, 533 нче, 2016 ел, 12 декабрь, 918 нче, 2017 ел, 21 март, 168 нче, 2017 ел, 12 сентябрь, 649 нчы, 2018 ел, 1 декабрь, 1070 нче, 2018 ел, 10 декабрь, 1093 нче, 2019 ел, 11 сентябрь, 814 нче, 2019 ел, 22 ноябрь, 1065 нче, 2019 ел, 30 декабрь, 1253 нче, 2019 ел, 30 декабрь, 1263 нче, 2020 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы, 2020 ел, 6 март, 180 нче, 2020 ел, 31 август, 759 нчы, 2020 ел, 22 сентябрь, 853 нче, 2020 ел, 22 декабрь, 1177 нче, 2021 ел, 12 февраль, 71 нче, 2021 ел, 17 июнь, 466 нчы, 2021 ел, 15 декабрь, 1238 нче, 2022 ел, 24 февраль, 158 нче, 2022 ел, 27 апрель, 396 нчы, 2022 ел, 26 сентябрь, 1034 нче, 2022 ел, 22 декабрь, 1393 нче, 2022 ел, 29 декабрь, 1441 нче, 2023 ел, 2 май, 558 нче, 2023 ел, 22 май, 622 нче, 2023 ел, 19 июль, 863 нче, 2023 ел, 23 ноябрь, 1499 нчы, 2023 ел, 27 декабрь, 1691 нче, 2024 ел, 25 июнь, 458 нче, 2024 ел, 26 сентябрь, 835 нче, 2024 ел 27 ноябрь, 1066 нчы, 2025 ел, 30 апрель, 286 нчы, 2025 ел, 30 декабрь, 1208 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле 4.1.9[1] пунктча өстәргә:

4.1.91. Бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә республика башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы булып тора.

Түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

юридик затка яисә индивидуаль эшкуарга эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъекты статусы бирү;

Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары реестрын булдыру һәм алып бару;

Татарстан Республикасында бизнесны җаваплы алып бару торышын мониторинглау, шулай ук бизнесны җаваплы алып бару өлкәсендә хокук куллану мониторингы;

бизнесны җаваплы алып баруны үстерү өлкәсендә республика башкарма хакимияте органнары эшчәнлеген координацияләү, методик һәм методологик озата бару, шул исәптән дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә.»;

4.1.26 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасында эшкуарлык эшчәнлегенең җаваплы субъектлары реестры.».

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин